КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 май г.Казань № 313

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы үткәрелә торган көннәрдә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы үткәрелгәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге объектларда 8 сәгать 00 минуттан алып 17 сәгать 00 минутка кадәр алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми дип билгеләргә:

2024 елның 14 маеннан 17 маена кадәр Казан шәһәренең Астрономия, Бауман, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Профсоюз, Университет, Чернышевский урамнарында урнашкан сәүдә объектларында (җәмәгать тукланыуы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш);

2024 елның 15, 16 һәм 18 маенда Казан шәһәренең Спартак урамы, 2 нче А, 6 нчы йортлар; Һади Такташ урамы, 2, 21, 77 нче йортлар; Марсель Сәлимҗанов урамы, 2, 6, 12 нче А, 15/8 нче Б, 17 нче йортлар адреслары буенча урнашкан сәүдә объектларында (җәмәгать тукланыуы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш).

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, кертелә торган чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм, килештереп, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин